ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УСАД АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Усад авылы, Совет ур.,41

СОВЕТ УСАДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Усады, ул. Советская, 41

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

---

КАРАР
12 ноябрь 2019 ел

РЕШЕНИЕ
№ 195

## Җирле салымнар буенча недоимкаларны, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты һәм “Төбәк салымнары буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында”, 2017 елның 19 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советы,

КАРАР ИТТЕ:

1. Түбәндәге җирле салымнар буенча недоимкаларны, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләрне билгеләргә (алга таба – бурыч):

- җир салымы һәм мирас хокукыннан баш тарткан яки варислары булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирасны кабул итмәү очрагында үлгән физик затларның салымы буенча.

1.1. Салым түләүченең бурычын бетерү салым органы тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә тормышка ашырыла:

- әлеге карар;

- недоимкалар һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар суммасы турында физик затның яшәү урыны буенча салым органыннан белешмәләр;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 85 статьясы 3 пункты нигезендә салым органына кергән физик затларның гражданлык хәле актларын теркәүне тормышка ашыручы орган тарафыннан физик затның үлү фактын теркәү турында мәгълүматлар;

- салым органының мираска хокук турында шаһәдәтнамә бирү турында мәгълүматлар булмавы турында белешмә.

1.2. Әлеге карар бурыч килеп чыккан вакыттан килеп туган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе урынбасары,
Җирлек башлыгы урынбасары Д.В.Нигметзянова